РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ГЛАВА ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

Ленина ул., д. 46, с. Тюлячи, 422080

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ

Ленин ур., 46 нчы йорт, Теләче авылы, 422080

тел. (факс): (843) 602-11-89, E-mail: telache@tatar.ru, http://tulachi.tatarstan.ru/

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

**№ 16** **« 10 » апреля 2017 г.**

Теләче муниципаль районында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 елның 21 мартындагы 515-р номерлы боерыгын гамәлгә ашыру турында

Хезмәтне саклау мәсьәләләренә җәмәгатьчелек игътибарын җәлеп итү, җитештерү өлкәсендә бәхетсезлек очракларын һәм һөнәри авыруларны булдырмау, шулай ук Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 елның 21 мартындагы 515-р номерлы күрсәтмәсе нигезендә хезмәт тртибен барлык өлкәләргә дә таныту максатларында

,

1. Теләче муниципаль районы җирле үзидарә органнарына 2017 елның 10 апреленнән 30 маена кадәр «Хезмәтне саклау буенча мәгълүматларны җыюны һәм куллануны оптимальләштерү»девизы астында Бөтендөнья хезмәтне саклау көненә багышланган чараларда катнашырга.

2. Авыл җирлекләренең җирле үзидарә органнарына, оешмаларга, предприятиеләргә һәм учреждениеләргә Бөтендөнья хезмәтне саклау көненә багышланган чараларны тормышка ашыруда, шул исәптән хезмәткәрләрне эш башкаруның куркынычсыз алымнарына өйрәтүне оештыру, хезмәтне саклау һәм хезмәтне саклау кагыйдәләрен һәм нормаларын үтәү, хезмәтне саклау көннәре, «түгәрәк өстәл» утырышлары, киңәшмәләр, смотр-конкурслар үткәрүдә актив катнашырга тәкъдим итәргә.

3. «Татмедиа» АҖ филиалы «Теләче-информ» мәгълүмат үзәгенә акцияне массакүләм мәгълүмат чараларында яктыртуны, урманга сак караш турында материаллар бастыруны һәм чыгаруны тәэмин итүне тәкъдим итәргә.

4. Әлеге боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе Р.Р. Нуруллинга йөкләргә.

И. Ф. Зарипов